МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “09” 03 2016 № 93

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибе хакында

Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә аерым дәүләт вазыйфаларында, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларында булучыларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр һәм башка төр аерымлык билгеләре алулары тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2015 елның 10 октябрендәге 506 номерлы Указының 4 пунктын, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнелә һәм азат ителә торган дәүләт вазыйфаларында булучы затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалардан мактаулы һәм махсус исемнәр, бүләкләр һәм башка төр аерымлык билгеләре алулары тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2016 елның 12 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы Указының 3 пунктын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүе тәртибет урында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 9 мартындагы
93 нче номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, Бүләкләрен кабул итүе тәртибе турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен (алга таба - исемнәр, бүләкләр) кабул итү тәртибе билгеләнә.

2. Мактаулы исем, бүләк алганда дәүләт хезмәткәре Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрыннан (алга таба - министр) рөхсәт алырга тиеш.

3. Чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка ижтимагый берләшмәдән һәм дини оешмадан исем, бүләк алган яки алачаклыгы турында искәртелгән дәүләт хезмәткәре өч эш көне дәвамында дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (алга таба – кадрлар бүлеге) чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка ижтимагый берләшмәдән һәм дини оешмадан мактаулы исем, бүләк алуга рөхсәт бирү турында әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган үтенеч язуы (алга таба –үтенеч язуы) тапшыра. Үтенеч язуын карау вакыты үтенеч язуы әлеге Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә кадрлар бүлегендә теркәлгән көннән соңгы 10 эш көнен тәшкил итә.

4. Мактаулы исемнән, бүләктән баш тартучы дәүләт хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар бүлегенә чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка ижтимагый берләшмә һәм дини оешмадан мактаулы һәм махсус исем, бүләк алудан баш тарту турында әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган хәбәрнамә тапшыра.

5. Мактаулы исемне, бүләкне Министр үтенеч язуын карау нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнче алган дәүләт хезмәткәре мактаулы исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен аларны алганнан соңгы өч эш көне дәвамында кадрлар бүлегенә җаваплы саклаунышка тапшыра. Бу

вакытта әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтадагы форма буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Дәүләт хезмәткәре эш командировкасында мактаулы исем, бүләк алса яки аларны алудан баш тартса, үтенеч язуын яки хәбәрнамәне тапшыру вакыты дәүләт хезмәткәренең эш командировкасыннан кайткан көненнән башлап исәпләнә.

7. Дәүләт хезмәткәре аннан тормаган сәбәпләр аркасында үтенеч язуын яки хәбәрнамәне, мактаулы исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен әлеге Нигезләмәнең 3-5 пунктларында билгеләнгән вакытлар эчендә тапшыра алмаганда ул үтенеч яки хәбәрнамәне, мактаулы исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәп беткәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтадагы форма буенча тутырылган үтенеч язуларын (хәбәрнамәләрне) теркәү журналына теркәү аның керү көнендә кадрлар бүлеге тарафыннан башкарыла. Теркәлгән үтенеч язуын (хәбәрнамәне) кадрлар бүлеге карау өчен ике эш көне эчендә министрга юллый.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне эчендә дәүләт хезмәткәренә министрның үтенеч язуын карау барышында кабул ителгән карары турында хәбәр итә һәм аңа, имза куйдырып, үтенеч язуының министр резолюциясе салынган, кадрлар бүлеге мөһере белән расланган күчермәсен тапшыра. Үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) министр резолюциясе салынган төп нөсхәсе дәүләт хезмәткәренең шәхси делосына теркәлә.

10. Дәүләт хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуы министр тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта кадрлар бүлеге 10 эш көне дәвамында дәүләт хезмәткәренә мактаулы исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Бу вакытта әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтадагы форма буенча кабул иту-тапшыру акты төзелә.

11. Министрның дәүләт хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тартуы очрагында кадрлар бүлеге 10 эш көне эчендә мактаулы исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини оешманың тиешле органына юллый.

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүетәртибе турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт
һәм юл хуҗалыгы министрына

______________________________
(Ф.И. Ә.и.)

______________________________

______________________________
(Ф.И. Ә.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алырга рөхсәт турында
үтенеч язуы

Миңа_______________________________________________________________

_____________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен кем тарафыннан бирелгән исем, нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

_____________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемгә,бүләккәдокументлар тапшыру вакыты һәм урыны)

алуга рохсәт бирүегезне сорыйм.

Мактаулы яисә махсус исем алуга документлар, бүләк һәм аңа документлар, башка аерымлык билгесенең документлары (тиешлесенең астына сызарга):
_____________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

_____________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнгә, бүләккәдокументлар атамасы)

20__ елның“___” __________________номерлы тапшыру-кабул итү акты буенча
_____________________________________________________________________
(кадрлар бүлекчәсенең атамасы)

“__” ______________ 20 __ ел ______________ ______________
(имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүетәртибе турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт
һәм юл хуҗалыгы министрына

______________________________

______________________________
(Ф.И. Ә.и.)

______________________________

______________________________
(Ф.И. Ә.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең һәм дини оешманың мактаулы һәм махсус исемен, бүләген кабул итеп алудан баштартутурында
хәбәрнамә

Минем тарафтан ________________________________________________
(мактаулы яисә махсус исемнең, бүләкнең атамасы)

________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен кем тарафыннан бирелгән исем, нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

алудан баш тарту турында карар кабул ителүе хакында белдерәм.

“__” _____________ 20 __ ел      ____________      ____________
(имза)      (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүтәртибе турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Кабул итү-тапшыру
акты

“__” _____________ 20 __ ел №

Без, түбәндә имза куючылар,_______________________________________________
(Ф.И. Ә.и., вазыйфасы)
___________________________________________________________________________
тапшыруы / кабул итүе (тиешлесенең астына сызарга),дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең вазифа заты ____________________________________________________
(Ф.И. Ә.и.)
түбәндәгелэрне кабул итуе/тапшыруы (тиешлесенең астына сызарга) турында акт тезедек:

| № п/п | Атамасы | Күләме (данә) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |

Тапшырды | Кабул итте
___________________________ | ___________________________
(имза)(имзаны шәрехләү) | (имза)(имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итүетәртибе турында Нигезләмәгә
4 нче кушымта

# Үтенеч язуларының (хәбәрнамәләрнең) исәбен алып бару ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) тапшыручы дәүләт хезмәткәренең Ф.И.Ә.и. | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) тапшыручы дәүләт хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенеч язуы (хәбәрнамә) керү көне | Бүләкнең, мактаулы исемнең атамасы | Кабул итү-тапшыру акты реквизитлары (булса) | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) кабул итүче затның имзасы, Ф.И.Ә.и. | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) тапшыручы затның имзасы, Ф.И.Ә.и. | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |